СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

22 ноябрь, 1997ел. ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 132 (8144) | Бәясе билгеләнгәнчә

## 1957 - 1997 Татарстан Журналистлар берлегенә - 40 ел

*19 ноябрь көнне «Казан» милли мәдәният үзәгендә Татарстан Журналистлар берлеге оешуга 40 ел тулуга багышланган тантана уздырылды. Әлеге оешманың тарихы һәртөрле вакыйгаларга гаять бай 1918 елга барып тоташа. Ул чакта Мәскәү каласында Россия Журналистлар берлегенең I съезды үткәрелә. Җөмһүриятнең әлеге иҗади берләшмәсе исә ныклап торып 1957 елда гына аягына баса. Хәзер ул үз сафларында 700гә якын кешене берләштерә. Аларның яртысы - ветераннар. Шуңа да берлекнең иң мөһим бурычы - каләм ияләрен социаль яктан һәм хокукый яклау.*

## Татлы тамырны - дәүләткә «Родина»ның өлеше - 4 меңнән ишле

Шикәр чөгендере сату буенча килешү йөкләмәсен тагын бер хуҗалык тутырды. «Родина» игенчеләре шикәр заводына 3840 урынына 4126 тонна чимал китерделәр. «1 нче Май» килешү йөкләмәсеннән тыш 200 тоннадан артыграк чөгендер сатты. Озатыласы чөгендер бу культураны иң ишле мәйданда иккән «Киекле»дә генә калып бара.



**Газ һәм электр белән эретеп ябыштыручы хезмәте зур җаваплылык таләп итә. Әхәт моны һәрдаим тоя. Шуңа да нинди объектта эш башкарса да, хезмәтенә бөтен күңелен бирә ул. Төзелештә монтаж эшләре алып барганда, җитәкчелек иң җаваплы эшләрне аңа беркетә. Турыдан - туры техника белән бәйле эретеп ябыштыру эшләренә дә үтә җаваплы карый ул, чөнки белә: җөйләрне аз гына дөрес тоташтырмасаң да, азагы аянычлы булырга мөмкин моның.**

**Әхәт Ногъманов - 5 нче колоннаның иң тәртипле, уңган эшчеләренең берсе.**

**- Алтын куллы егетебез ул безнең,- ди аның турында идарәнең баш инженеры Х.Сәлахов та. - Эшнең берсеннән дә курыкмый, ал - ял белән санашмый.**

**Рәсемдә: УТТ эретеп ябыштыручысы Ә.Ногъманов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## КОТЛАУ

### Хөрмәтле хезмәттәшләр!

**Җәмгыятебездә үткәрелә торган реформаларның реаль казанышларыннан берсе булып мәгълүмлелек тора.**

**Бүген без билгеләп үтә торган вакыйга Журналистлар берлегенең үзе өчен генә түгел, ә бөтен республика өчен дә әһәмиятле, чөнки бу оешма гомер - гомергә матбугат хезмәткәрләренең һөнәри мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклап килде, республика журналистикасының югары дәрәҗәсен сакларга омтылды.**

**Журналистларга кешенең төп хокукларыннан берсе булган хокукын - аның мәгълүматка, сүз ирегенә хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү кебек мактаулы бурыч йөкләнгән. Еш кына иҗтимагый фикер формалашуга, җәмгыятьтәге психологик һәм иҗтимагый - сәяси климатка, атмосферага тәэсир итүче мәгълүмат кыры нәкъ менә аларның хезмәте белән булдырыла. Шуңа да журналист һөнәре - эшкә җаваплы караучы һәм намуслы кешеләр һөнәре ул.**

**Бүген җәмгыятебезнең шактый зур өлеше тулаем җәмгыятьтне дә, аерым кешеләрнең тормышын, гамәлләрен дә икътисадый, иҗтимагый - сәяси, дәүләти һәм әхлакый яктан төзүнең дөрес юлларын эзләү белән мәшгуль. Шуңа да журналист профессиясе - үзләре алына торган темаларны белеп һәм тирән яктыртучы компетентлы кешеләр һөнәре дә.**

**Шул ук вакытта бүген матбугатта мәгълүмлелек журналистларның тормышы өчен зур хәвеф белән дә янәшә тора. Шуңа да журналист һөнәре безнең заманда чын мәгънәсендә кыю кешеләр һөнәренә әверелде. Болар һәммәсе дә журналистлардан үзләренең һөнәри мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итү өчен берләшүләрен таләп итә.**

**Шуңа күрә дә бүгенге юбилей көннәрендә республикабызның журналистлар оешмасы тормышына катнашы булган, Россия һәм Татарстан журналистлар берлеге елъязмасына алтын сәхифәләр язган кешеләрнең барчасын да рәхмәт хисләре белән искә алу белән бергә, Берлекнең бүгенгесе һәм иртәгәсе, формаль яктан элеккечә калсалар да, асылда һичшиксез бик нык үзгәргән бурычлар турында да уйлау өчен уңайлы форсат булып тора.**

**Республикабыз Журналистлар берлегендәге һәркемне истәлекле дата белән котлап, киләчәктә бу оешма тагын да тупланганрак, журналистлар цехының үз эчендә генә түгел, аннан читтә дә зур абруйга ия булыр дип ныклы ышаныч белдерәсе килә.**

**Матбугат вәкилләренең һөнәри осталыгын күтәрү, журналистларның профессиональ этикасы үтәлешен тәэмин итү, аларның хезмәт һәм көнкүреш шартлары белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатыннан безгә бергәләп эшләү өчен мәйдан киң. Ахыр чиктә Татарстанда чын мәгънәсендә демократик җәмгыять формалаштыруга матбугатның йогынтысын көчәйтү буенча уртак эшебез бит ул.**

**И.ӘХМӘТҖАНОВ,**
**Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министры.**

## Кар өстендә... урак өсте

Ни генә әйтсәң дә, барыбер кинәндерде быел бу «Кейс»лар безнең игенчеләрне. Башта әллә никадәр мәйданда егылган - чәбәләнгән бодайны җыеп бирделәр, үз комбайннарына гына авырга килгән кайбер хуҗалыкларның кем әйтмешли ярты уракларын да шулар урды әле. Күрше Әлки һәм ерак кына Бөгелмә районнары игенчеләренә дә булышып кайтышларына МТСчыларны икенче бер мөһим эш - кукуруз урагы көтеп тора иде инде. Дөрес, кукуруз чәкәне җыя торган җайланмалар комбайннарның бишесенә генә тиде әлегә. Алай да орлыкка калдырылган кукурузның шактые алар өлешенә насыйп булды. «Кейс»ларны якын җибәрмим дип торучылар да быел алар ярдәменә мөрәҗәгать итми булдыра алмадылар. Ник дигәндә, хуҗалыкның үзендәге юклы - барлы бер комбайн белән генә шактый ишле мәйдандагы кукурузны, көннәр дә чын - чынлап көзгә кереп киткәндә кайчан суктырып бетерәсең ди. Шуңа күрә МТСның «Кейс»лары, «Агрохимсервис»ның КамАЗларыннан торган мобиль отрядларга чират булды да. Егетләрнең берсенең дә эшенә тел - теш тидерерлек булмады. Шулай да Александр Виноградов белән Вячеслав Герасимов аерым мактауга лаеклар. Беренчесенең исеме урак өстендә газетабыз битләрендә алдынгылар исемлегеннән төшмәгәнлеген укучыларыбыз хәтерли торгандыр. Ярдәмчесе Алексей Федоров белән озак кына берәүгә дә тоттырмый барды алар. Урак бетәр - бетмәстә Леша укырга китеп барды (студент кеше бит) һәм Александр «Кейс»ы белән икәүдән - икәү генә калды. Алмашчысыз эшләүче комбайнчылар районда аз түгел анысы, әмма бит аларның хәле бөтенләй башка, алар үз авылларында, урак чоры никадәр киеренке булса да аны барыбер үзләренчәрәк көйли алалар. Ә болар бит җыелма отряд составында, күчмә шартларда, бер хуҗалыкта башланган эшне ничек тә тизрәк бетереп икенчесенә күчү өчен көне - төне штурвал артында булырга кирәк. Һәм шундый киеренкелек шартларында гаять зур чыдамлылык күрсәтте Александр, ялы - йокысы хисабына булса да уракта башкалардан калышмады. Кукуруз урагына Вячеслав Герасимов та «ялгыз» гына чыкты.(Әле шушы арада гына анысының рәсемен газетабызның беренче битендә бастырдык). Без барып чыкканда «Үрнәк»нең Зирекле кырында шул ике фидакарьнең комбайны гына иде. Элекке көнне «Чирмешән»дә эшне төгәлләгәннәр дә, инде кичке караңгы төшүгә карамастан Биляр Озерога күченгәннәр. Килү белән эшкә дә тотынганнар. Монда төне буе эшләп, иртәнге дүрттә Зирекле кырында була инде комбайннар. МТСның директоры Якуб Ибраһимов үзе дә яннарыннан бер минутка да китеп тормый, әле комбайннарына үзе утырып эшләп егетләрне чиратлап ял да иттерә. Чәршәмбе көнне кичкә якка шактый мәйданны эш иткәннәр иде инде. Кар өстеннән баручы ул «Кейс»ларны безгә китаплардан һәм кинолардан гына таныш булган бары бер күренеш - мамык җыю белән генә чагыштырырга мөмкиндер инде хәзер - кукуруз басуы чыннан да ап - ак мамык кырын, ә кар бүрекләр кигән чәкәннәр мамык тартмачыкларын хәтерләтә. Хәер, анысы читтән карап торган кешегә генә шулай күренә торгандыр. Ә комбайнны кар өстеннән йөртеп, кар катыш кукуруз чәкәннәрен ничек тә сабакта калдырмыйча җыеп алырга тырышуның никадәр киеренкелек соравын егетләр үзләре генә белә. Коры көннәрдә күккә төбәлеп утырган чәкәннәрнең шактые инде башларын аска игән, шуңа күрә ургычка эләкми калганнары була икән, моның өчен берәүне дә гаепләрлек түгел - әле дә әнә кирәге чыга калса дип басу читендә К - 700 дежур тора. Шөкер, анысы кирәксә дә күбрәк КамАЗларга кирәк булгалый. Сүз уңаеннан «Агрохимсервис» егетләренең дә бу зур эштә баштан ахыргача булуларын билгеләп үтми мөмкин түгел. Комбайннарның алар аркасында тоткарланганы юк инде хәзер - сәгате - минуты кадерле чакта анысы бигрәк тә мөһим бит.

....Ул төнне Фәрит Җәлалов белән Владислав Ульдяков теге ике комбайнчыга ял биргәннәр, иртән исә өченче комбайн белән Гайфетдин Насыйров та аларга кушылган. Өчәүләп күрше «Игенче» колхозы кырын төгәлләгәннәр. Ремонтка кергән ике комбайн да чыккач, тагын ике - өч көнлек эш калып бара инде егетләргә. Әнә шулай, уракның кар өстендәгесенә дә нокта куеласы.

Р.МУЛЛИН.

# КАЙСЫГЫЗНЫҢ ӨЕ ҖЫЛЫ?



**Норлат җылылык предприятиесе өчен бүген киеренке, катлаулы һәм җаваплы чор: җылыту сезоны бара. Бу - шәһәрнең үзәк өлешендәге 189,3 мең квадрат метрны тәшкил иткән торак йортларда яшәүче халык җылылык предприятиесенең 5 котельныена күз кебек карап, зур өметләрен баглап тора дигән сүз. Ләкин, кызганычка каршы, алар һәрвакытта да акланмый: өйләрдә җылылык кулланучы теләгәнчә үк дәрәҗәгә җитми. Менә шул вакытта котельный, җылылык челтәре хезмәткәрләренә карата, йомшак итеп әйткәндә, "җылы булмаган сүзләр" юллана да. Ләкин аларның һәркайсы да гадел микән соң? Кайчакта батареяларга җылылык җитешмәүнең сәбәпчесе кулланучы үзе яки аның күршесе түгелме соң?**

**Бу язмада шул сәбәпләргә тукталачакбыз.**

Исәпләүләр буенча халыкның суны батареялардан алып файдалануы системада җылылык югалуга китергән иң зур фактор. Урланган су микъдары күбрәк булган саен, Җылылыкта шул кадәр кими дияргә мөмкин. Ә бит җылылык челтәре куллана торган "җылылык энергиясеннән файдалану кагыйдәләре" нигезендә челтәрдәге суны законсыз рәвештә файдаланган өчен кулланучы 5 тапкыр артыграк түләргә тиеш. Факт урынында тотылган кешегә шунда ук акт төзелә, ул актка имзасын куюдан баш тарткан очракта җаваплылыктан котыла алмый, ахыр чиктә аңа җылылык килүне туктату чаралары күрелә.

Җылылык челтәре хезмәткәрләре бу мәсьәләдә рейдлар үткәрәләр. Шул чакта төрле очракларны күзәтергә туры килә: кулланучылар батареялардагы кайнар су белән машиналар юалар, көнкүрештә файдаланалар - бу максатта хәтта аны салкын су белән катнаштыралар. Әлбәттә, аларның бу гамәлләре җылылык системасындагы суның никадәр зарарлы булуын аңламаудан башкарыладыр. Хикмәт шунда ки, казаннарны юшкын утыртмыйча, озаграк хезмәт итүләренә ирешү өчен суга ОЭДФ кислотасы кушыла. Суга аның исе дә, төсе дә чыкмый, ләкин кулланучы сәламәтлегенә нык зыян китерә: шундый суны күп тапкырлар файдалану аллергик һәм нерв авырулары китереп чыгарырга мөмкин.

Предприятие мәнфәгатьләре ягыннан караганда, җылылык системасында суның югалуы көйләнгән гидравлик режимны боза һәм зур матди зыян китерә. Санларга күз салсак, кайнар су арзан түгел: котельныйларның өчтән берендә бер айга 10 мең кубометрга кадәр су юкка чыга, бу 100 млн.га якын акчаның җилгә очуы дигән сүз. Әлеге чыгымнарның күп өлеше кулланучыга түгел, ә предприятие һәм бюджет "җилкәсенә" төшә. Ә бер өлеше тигез рәвештә һәр кулланучыга бүленә. Һәм шунысы кайбер кулланучы өчен гаделсез факт булып тора да: суны бит һәркем дә урламый, шуңа карамастан, кем өчендер түләргә туры килә. Чөнки әлегә шәхси йортларда файдаланылган суны үлчәгеч приборлары юк. Һәм нәкъ шул максатта предприятие киләчәктә һәркемнең индивидуаль счетчигы булуы зарур дигән юнәлеш алып барада. Әлегә мондый счетчиклар НПТСта, ул шәһәр буенча күпме су югалганын исәпләргә мөмкинлек тудыра һәм шәһәрнең хәллерәк предприятиеләрендә генә урнаштырылды. Нәкъ шул приборлар суны экономияләүгә этәрә. Бу факт счетчиклы предприятиеләргә инде мәгълүм: алар суны аңа карап агызалар.

Гомумән, шунысын әйтү мөһим: җылылык системасыннан су күбрәк югалган саен җылылык энергиясенең үзкыйммәте дә шулкадәр арта. Димәк, Норлатта су урлау нигездән юкка чыгарылса, җылылык өчен түләү дә күпкә кимер иде.

Еш кына өй эчендәге системаны юдырмау, үткәргечләрне изоляцияләмәү аркасында да өйләрдә җылылык җитәрлек булмый. Мәсәлән, МСОда ел саен җылылык үткәргечләре сезонга әзерлексез рәвештә керә.

Җылылык трассасы өстенә яки аңа терәтеп гаражлар салу да зур проблемага әйләнде соңгы вакытта. Авария очракларын булдырмау, ягъни сак зонасын капламау йөзеннән НПТС шундый хуҗаларны катгый кисәтә. Хәзер мунчаларга, гаражларга җылылык кертүчеләр күбәйде, ләкин алар җылылык белән файдалану кагыйдәләрен күздә тотмыйча рөхсәтсез эшләнә, ягъни җылылык системасы җайланмый. Норма буенча диаметры 3 мм.дан артмаган шайба куелмый. Нәтиҗәдә линиядә иң соңгы йортларга җылылык җитәрлек дәрәҗәдә килеп җитми.

Кайчакта олырак яшьтәге кешеләр өйдәге салкынлыктан зарланып киләләр, тик барып үлчәп карагач анда температураның 20 - 22 градус икәнлеге ачыклана. Бу тиешле нормадан ким түгел: түләү бары тик 20 градус өчен генә алына.

Димәк, өйләребез җылы булмавында җылылык челтәре предприятиесен гаепләргә ашыкмыйк әле. Тирә - ягыбызга әйләнеп карыйк: җылыны саклау өчен барысын да эшләгәнбезме соң, куллану кагыйдәләрен бозмыйбызмы? Җавап тискәре булса, аны төзәтергә әле соң түгел.

**Ф.ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
**НПТСның ПТО инженеры.**

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА,**
**газета корреспонденты.**

## Ахырзаман алдыннан кеше башына тычкан җитәр

Русиядә тычкан бизгәге авыруы котыра. Аны тычканнар һәм күселәр тарата. Бу чир эләккәч башта кешенең тән температурасы 39 - 40 градуска кадәр күтәрелә. Аннары бик каты башы авырта башлый, мускуллар сызлый, күзләр авырта, гел су эчәсе килеп тора, тамак чатный. Борыннан, аналыктан, ашказаныннан кан китә башларга мөмкин (бу очракта инде исән калып булмый). Чирнең тагын бер нәтиҗәсе - бөерләр эштән чыга.

Кешеләр тычканнар һәм күселәрдән бүленеп чыккан сыеклык эләккән азыкны ашап, шулай ук бу хайваннарны кулларында тотсалар зарарланалар. Инфекция үпкәләргә тузан белән дә керә. Нигездә 20 - 50 яшьлек кешеләр авырый, бигрәк тә ир - атлар.

Русиядә тычкан бизгәге аеруча Урал, Идел буе һәм Идел - Нократ төбәкләрендә киң таралган. Быелның тугыз аенда гына да 8,5 мең кеше авырды, шуның 35е үлде. Авыруларның яртысы - Башкортстанда яшәүчеләр. Удмуртиядә, Татарстанда, Пенза, Саратов, Ульяновск өлкәләрендә дә авыру очраклары күп теркәлгән.

Хәлләр бик җитди. Тычкан бизгәге эләктерүчеләрнең 30 процентының гомерләре буе бөерләре авыртачак, күбесенә ясалма бөер кирәк.

Бу чирдән ничек котылырга соң? Җавап бер генә: өйдә булган тычкан - күселәрне юк итәргә. Үзегез генә булдыра алмасагыз, урыннардагы санэпидстанцияләргә мөрәҗәгать итегез. Базларда, сарайларда сакланган җиләк - җимешләрне ашар алдыннан яхшылап юыгыз. Тычканнар авыз иткән ярмаларны ташлагыз. Бу чиргә каршы әлегә бернинди дару да уйлап табылмаган.

**("Татарстан яшьләре" газетасыннан).**

## Аракы бәясе тагын арта?

20 градуска кадәрге ликер - аракы эчемлекләре ясауга китүче этил спиртына акция салымы киләсе елның 1 гыйнварыннан 50 процентка кадәр күтәрелә. Бу яңалык Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы предприятиеләре җитештергән алкоголь эчемлекләренең сыйфатын күтәрү һәм сатылуын арттыру чаралары турында"гы карарына өстәмәләр кертү белән бәйле. Шулай итеп, яңа елдан аракы бәяләре күтәрелү ихтималы бар.

***

Казандагы метро төзүчеләр беренче метро станциясе төзи башлауга 80 миллиард сум акча тотканнар инде.

***

Җир шары тирәли сәяхәткә чыккан Казанның "Норд Стар" яхтасы Стамбулга барып җиткән.



Яшь аермалары шактый булса да бу ике механизаторны байтак сыйфатлар берләштерә. Виктор Николаевич Герасимов та, Сергей Александрович Куприянов та МТЗ - 80 тракторларында эшлиләр. Җәйләрен алар җәмәгать маллары өчен азык әзерләү звеносы составында хезмәт куялар, малларга елның - елында мул итеп азык туплап калдыру өчен тырышалар. Соңгысы гаҗәп түгел, чөнки механизаторлар кышын ферма терлекләре өчен азык ташуга күчәләр, аларны тулы рацион белән ашатуга үзләре үк өлешләрен кертәләр.

Герасимов һәм Куприянов хәзер нәкъ шул хезмәттә. Терлекчеләр аларның эшеннән канәгатьләр: механизаторлар һәрвакыттагыча вазифаларына төгәл һәм җаваплы карыйлар.

Сүз уңаеннан, Герасимов үзенә лаеклы алмаш та әзерләүгә ошый: улы Евгений 2 җәй инде уракта комбайнчы ярдәмчесе булып эшли. Олылар аңарда хәзер үк әтисе чалымнарын күрәләр: булдыклы, тырыш, җаваплы.

**Рәсемдә: "Родина" КХАсы механизаторлары В.Н.Герасимов һәм С.А.Куприяновны фотохәбәрчебез Н.Азизов җәйге кызу эш вакытында фотога төшергән булган.**

## ЯРТЫ ГАСЫРДАН СОҢ ОЧРАШУ

Егоркино авылында күптән түгел моннан 50 ел элек авыл мәктәбенең беренче классына баручыларның очрашуы булды. Ул чакта, 1947 нче елда мәктәп бусагасын 30дан артык сабый атлап кергән булса, бүген 10нан аз гына күбрәк кеше җыелды. Тормыш аларның кайсысын кая таратып ташлады.

Очрашуыбыз Елена Терентьеваның кунакчыл өендә, өстәл артында барды. Үзебезнең беренче укытучыларыбыз, бу дөньяны вакытыннан элек ташлап киткән чордашларыбыз һәм, гомумән, һәрберебез турында җентекләп сөйләшү булды. Классташларыбыз арасында механизаторлар һәм терлекчеләр дә бар иде. Иң куанычлысы - һәрберебез үз оныклары турында да яратып сөйләделәр. Людмила Мусина, Анисия Шерникова, Владимир Яллин, Иван Алексеев, Анатолий Граф, Николай Емельянов бу сәгатьләрдә үзләрен бик бәхетле тойдылар.

Бу очрашу истәлеге итеп без күмәк фото алдык. Әлеге эчкерсез күрешүне оештырулары өчен Елена Терентьева һәм Иван Алексеевка әле дә рәхмәт укыйбыз.

**В.ТРОФИМОВ.**

# Безгә язалар

Безгә язалар




## Алар һаман сафта

70 яшен тутырып килүче агайларның егетләрчә балта уйнатып эшләүләрен күреп, үз алдыма: сөбханалла, күз генә тимәсен! 70 яшь әле картлык түгел икән, җитлегеп җиткән чак, тирән акыл белән яшәүнең, хезмәтнең кадерен, тәмен белеп яши торган чак икән дип уйлап куйдым. Бу агайларның хезмәт юлының башы ерак еллар аръягына - Ватан сугышы елларына барып тоташа. Алар кулы аша нинди генә эшләр үтмәгән. Лаеклы ялга китсәләр дә бүген дә алар сафта, хезмәткә булган мәхәббәтләре аларга рух, көч, дәрт бирә. Хезмәтне ярату - кешене чыныктыра, яшәртә икән - төз, нык буй - сыннары шуны раслап тора. 'Гаяз ага Гыймалетдинов гомерлек балта остасы. Гомер буе төзүчеләр бригадасын җитәкләде. Аларның тырыш хезмәте белән Чулпан авылында күп кенә терлекчелек бинаплары файдалануга тапшырылды. Культура йорты, мәктәп алар көче белән салынды. Пенсиягә китүенә күп еллар үтсә дә, бүген дә кулыннан балтасы төшми. Үзенең чордашлары Хәмит Зыятдинов, Васыйл Вәлиәхмәтов, Гәрәй Хафизов, Галиҗан Хәйдаров, Таһир Мортазин хуҗалыкның иң кирәкле эшләрендә намуслары кушканча булышалар. Үткән ел йөзләгән тонна бөртек сыешлы амбарны ремонтладылар. Быел терлекчелек биналарына ремонт ясадылар, дуңгызчылык фермасының түбәсен яптылар. Урып - җыюга хәзерлек вакытында ындыр табагында автоүлчәгечнең түбәсен яптылар, яннарын кадакладылар. ЗАВ - 20 агрегаты мәйданына бетон җәйделәр. Санап китсәң аларның хуҗалыкта башкарган эшләре бик күп. Һәркем сокланырлык хезмәт даны белән бизәлгән шәхси тормышларында да алар һәркемгә үрнәк.

Хезмәт юлын бергә узган замандашларыма саулык, бәхет, киләчәктә дә яшь, җитез, шат булып калуларын телим.

**М.УСМАНОВА.**
**«40 лет Победы» КХАсы.**

## Күңелле кичә

Авыл үзешчәннәре элек - электән бәйрәм уңаеннан концерт программалары әзерләп, спектакльләр куеп тамашачылар алдында осталыкларын күрсәткәннәр. Заманалар үзгәрсә дә, бу традицияләр әле дә дәвам итә... Татарстан Республикасы Конституциясе бәйрәмен авыл үзешчәннәре концерт программасы әзерләп каршы алдылар.

Ул көнне халык дөнья мәшәкатьләрен беразга онытып, рухи ял алу өчен культура йортына җыелды. Концерт балалар хоры чыгышы белән башланды. Балалар җыр - биюгә сәләтләрен күрсәттеләр. Авыл үзешчәннәренең матур җырлары да бәйрәм кичәсен ямьләндереп җибәрде. Сания Минһаҗева, Дания Мансурова, Халидә Гыйльметдиноваларның җырлары көчле алкышларга күмелде. Шулай ук Ринат Могыйнов, Ришат Атауллин, Илдар Яхиннарның моңлы җырлары тамашачылар күңеленә хуш килде. Эльмира Хәрләмова һәм Гөлнара Беляеваларның татар халык биюе, Алия Шиһапова һәм Люция Вәлиеваларның заманча ритмик биюләре нур өстенә нур булды.

Концертны Дания Мансурова үтә җанлы итеп алып барды. Баянда Андрей Константинов уйнады. Халык зур канәгатьләнү белән таралды.

**Зәкия ИСМӘГЫЙЛОВА.**
**Кычытканлы авылы.**

## «Чемет» почмагы

**Шәһәрдә үткәрелгән соңгы ярминкә көнне бу территориядәге ачык канализация коесына төшеп менүчеләр, билләһи, булды!**

### ЗЫЯНГА ТАРУЧЫ ЛЮКЫ

**Сез әле мондый коены**
**Бәлки, күрмәгәнсездер.**
**Төбендә ниләр барлыгын**
**Күреп менмәгәнсездер.**

**Мин үзем дә кое авызын**
**Күрмичәрәк килдем лә...**
**Шуңа аста ниләр барын**
**Туры килде күрергә.**

**Әле ярый баш сәламәт,**
**Маңгай төзек, күз исән.**
**Кыш кое гына ач икән**
**Әгәр үч алам дисәң.**

**Җир асты патшалыгына**
**Юл ачамы шәһәрләр?**
**Зәп - зәңгәр маңгаем белән**
**Йөрим кое каһәрләп.**



## 02 хәбәр итә

### Очкыннан ялкын кабына

дигән тәкъбирне онытып җибәрү кайчак аяныч нәтиҗәләргә китерә икән. Шәһәрнең Молодежная урамында яшәүче А. белән дә шулай була. Үз өендә эретеп - ябыштыру эшләре алып барганда очкын гына чәчрәгән була юкса, ә ахыры шактый зур янгын белән тәгалләнә. Менә бит халык әйтемнәрен онытсаң!

### Төркмәнстанга, сыер сатып

Әлбәттә, үз сыерын түгел, урланган ике сыерны сатып юллык акча эшләмәкче була качак З. Әлеге малларны Яңа Әлмәт авылындагы Г. йортыннан тыныч кына алып китеп Төрнәстә берсен иткә урнаштырып та өлгергән була. Менә икенчесе белән эш кыенрак килеп чыга - участок инспекторы сизеп ала. Шулай итеп, кояшлы Төркмәнстанга юл өзелә, ул кыскарак якка - район эчке эшләр бүлегенә юнәлергә мәҗбүр була.

### Соңгы көрәшү

Ульяновск шәһәреннән Л. өчен Норлат белән соңгы күрешү була бу юл. Берничә көн элек аның гәүдәсе «Кондырча» КХАсы территориясендәге вагончыкта табыла. Ул үзен - үзе үтерә.

### Яшел елан коткысында

Кызганычка каршы, соңгы вакытта яшел елан коткысына бирелеп тавыш - гауга чыгарырга яратучы хатыннар саны арта бара. Соңгы көннәрдә генә дә район эчке эшләр бүлегенең дежур частена яхшы гына кәефләнеп алган 5 хатын - кызны китерделәр - Төзүчеләр урамыннан 46 яшьлек Б., шикәр заводыннан М., 34 яшьлек О. һәм 2 яшь кыз - 1977 елгы Г. һәм 19 яшьлек Н. бер дә без хөрмәтләгән нәфис затларга охшамаган иделәр.


## САТАБЫЗ

**Гыйматдинов урамында 91 йортта 12 номерлы бер бүлмәле (30,3 кв.м.) фатир**

***

**Төргәктә яңа «Идел» газ плитәсе,бәясе-500 мең сум.**Адрес:Гыйматдинов урамы,47-2

***

**Ашыгыч рәвештә 1992 елгы УАЗ-469,кыйммәт түгел.**Адрес:Дружба ур., 70-9,16 сәг.тән соң

***

**Чистарту корылмалары районында базы белән капиталь гараж.**Адрес: Кормыш поселогы,Дружба урамы,21

***

**1997 елның сентябрь ахырында чыккан тентланган УАЗ-33036.**Тел:.5-21-94

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Агач эшкәртү станогы,такталар(5ле),ДВП (кыйммәт түгел) сатып алам.** Тел.:5-16-25

***

**Авылдагы яңа щит йортны барлык йорт яны корылмалары белән Норлатта өч бүлмәле яки бер һәм ике бүлмәле фатирларга алыштырабыз.** Адрес:Советская ур.,120-9.

***

**Ванналарны уникаль технология буенча эмаль белән каплау.Гарантия, сыйфат.**Бәясе-230000 сум.4 декабрьгә заявкалар 2-15-63 телефоны буенча кабул ителә.

**«Ивушка» балалар бакчасыннан кара төстәге ат югалды.**Күрүчеләрне бүләк бәрабәренә түбәндәге адрес буенча хәбәр итүләрен сорыйбыз:Молодежная ур., тел.:5-21-12 яки шәһәр советына(2-13-42).

**Гипстан чәчәкләп отделка эшләре башкарабыз,теләсә нинди стильдә гипстан штукатурка ясыйбыз.**Адрес:Дружба ур.,62-26

**Шәхси автомашиналар өчен арендага җылы гараж биреп торабыз.** Тел.: 5 - 11 - 95.

***

**«Коопзаготпром» территориясендә (Куйбышев ур., 98) тере мал сату буенча базар ачыла.** Эш вакыты - шимбә - якшәмбе көннәрендә 6дан 12гә кадәр.

***

**ВАЗ - 21063не «Нива»га алыштырам яки сатам.** Адрес: Солнечная ур., 7 - 2, 16 сәг.тән соң.

***

**Шәһәр үзәгендәге ике бүлмәле фатир ике берәр бүлмәлегә алыштырыла.** Адрес: Школьная ур., 13 - 11.

***

**Иванов Владимир Александрович исеменә машина йөртү таныклыгы һәм ВАЗ - 21061 техник торыш паспорты табучыны бүләк бәрабәренә иясенә кайтаруын сорыйбыз.** Тел.: 2 - 27-05.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.